ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Зур Кызыл ур. 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 9

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

«14» 01 2021 ел.

2020 елның 2 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2020 елның 2 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.

2. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен юлларга.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе урынбасары С.В.Заһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Документ создан в электронной форме. № 04-04/172 от 18.01.2021. Исполнитель: Архипова И.В.
Страница 5 из 7. Страница создана: 18.01.2021 09:19
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН